СОВЕТ ШУБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУБАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«29» май 2020 г. № 124

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советының кайбер карарларының үз көчен югалткан дип тану турында**

Гамәлдәге законнардагы үзгәрешләр белән бәйле рәвештә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Үз көчен югалткан дип танырга:

1.1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында " 2010 елның 27 февралендәге 5 номерлы карары ;

1.2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шубан авыл җирлеге Советының 2014 елның 13 ноябрендәге 111 номерлы «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы "Шубан авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карары.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми baltasi.tatarstan.ru сайтында бастырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Шубан авыл
җирлеге башлыгы: Р.Р.Мөҗипов.